СОВЕТ
ШЕМЯКОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ
МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ШӘМӘК
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

тел.(факс): (85563) 2-68-37; e-mail: Shmk.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение | Карар

“20” ноября 2018 ел | № 4-35

2018 елның 18 ноябрендә җирле референдумда кабул ителгән карарны теркәү турында

Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында» 2004 елның 24 апрелендәге № 23-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, 2018 елның 18 ноябрендәге җирле референдум нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге мәсьәлә буенча: «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәмәк авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 группа инвалидлар, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2019 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

**1. җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмиятле автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру:**

- Шәмәк торак пунктындагы юлларны вак таш җәеп ремонтлау;

- авыл җирлегенә караучы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту.

**2. Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру**

- урам яктырту объектларын модернизацияләү (Г. Тукай урамы буенча Шәмәк т. п. 5 нче чыбык үткәрү)

3. **Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итү:**

- Иске Чәбья торак пунктында су белән тәэмин итү системасын төзү, реконструкцияләү һәм ремонтлау

«ӘЙЕ» «ЮК»

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәмәк авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының 2018 елның 19 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Шәмәк авыл җирлеге территориясендә 2018 елның 18 ноябрендә үткәрелгән җирле референдум нәтиҗәләре турында» 928 номерлы территориаль сайлау комиссиясе карарын теркәргә..

2. Әлеге карарны муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

Мамадыш муниципаль районы
Шәмәк авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе И.Н.Зыятдинов